Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № XXV-5**

Балык Бистәсе штп. 2017 елның 28 декабре

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкына хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча «Татарстан Республикасы Армиягә, авиациягә һәм флотка (ДОСААФ) ярдәм итү буенча ирекле җәмгыяте» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Балык Бистәсе автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесенең эше турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкына хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча «Татарстан Республикасы армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Балык Бистәсе автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы З.Н. Җәләев мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы халкына хәрби-патриотик тәрбия бирү буенча «Татарстан Республикасы армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Балык Бистәсе автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесе башлыгы З.Н. Җәләев мәгълүматын (хәбәрен) игътибарга алырга;

2. «Татарстан Республикасы армия, авиация һәм флотка ярдәм итү ирекле җәмгыяте (ДОСААФ)» төбәк иҗтимагый-дәүләт берләшмәсенең Балык Бистәсе автомобиль мәктәбе» һөнәри белем бирү учреждениесенә (алга таба – ТР ДОСААФның Балык Бистәсе мәктәбе АМ ҺБУ) тәкъдим итәргә:

2.1) ТР ДОСААФның Балык Бистәсе мәктәбе АМ ҺБУ дә «В» категориядәге транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләүне дәвам итәргә;

2.2) Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районында патриотик, оборона-спорт чаралары үткәрергә, районда спортның техник һәм хәрби - гамәли төрләрен алга таба үстерү, районда үткәрелә торган хәрби-патриотик тәрбия чараларында катнашу өчен бөтен көчне куярга.

3. «Балык Бистәсе районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» дәүләт казна учреждениесенә үз компетенциясе кысаларында ТР ДОСААФның Балык Бистәсе мәктәбе буенча «В» категорияле машина йөртү таныклыгы булмаган эшсез гражданнарны укытуда, «В»категорияле транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләүдә ярдәм күрсәтергә тәкъдим итәргә.

4. «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесенә үз компетенциясе кысаларында Татарстан Республикасы ДОСААФның Балык Бистәсе урта мәктәбе буенча 16 яшькә җиткән балаларны укытуны оештыруда, «В»категорияле транспорт чараларын йөртүчеләрне һөнәри әзерләү программасы буенча ярдәм күрсәтергә.

5. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе Хәбибуллин Р. Х. ка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
район Советы рәисе вазыйфаларын башкаручы И.Г.Ибраһимов